| ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ НУРЛАТСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН | | ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ НУРЛАТ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ БАШКАРМА КОМИТЕТЫ |
|---|---|---|

ПОСТАНОВЛЕНИЕ КАРАР

10.09.2021 № 915

Нурлат муниципаль районы Башкарма комитетының
2021 елның 18 гыйнварындагы 21 номерлы
карарына үзгәрешләр кертү турында

Муниципаль норматив актларны законнар нигезендә китерү максатында, Татарстан Республикасы Нурлат муниципаль районы Башкарма комитеты

КАРАР БИРӘ:

1. Татарстан Республикасы Нурлат муниципаль районы Башкарма комитетының 2021 елның 18 гыйнварындагы 21 номерлы карары белән расланган Татарстан Республикасы Нурлат муниципаль районы мәгариф оешмаларында эшләүче педагогик хехмәткәрләргә - яшь белгечләргә Татарстан Республикасы бюджетыннан бирелә торган акчалар исәбеннән айлык кызыксындыру өстәмәләре бирү тәртибенә түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

3 пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә: «3. Әлеге Тәртиптә педагогик хезмәткәр - 35 яшькә кадәрге («Россия Федерациясендә яшьләр сәясәте турында» 30.12.202020 ел, 489-ФЗ номерлы Федераль законның 6 статьясындагы 3 өлешендә каралган очраклардан тыш), төп һөнәри белем бирү программалары һәм (яисә) һөнәри белем бирү программалары буенча укуларын тәмамлаган, беренче тапкыр алган квалификация нигезендә эшкә урнаша торган Россия Федерациясе гражданы яшь белгеч дип танылa.».

2. Татарстан Республикасы Нурлат муниципаль районы Башкарма комитетының «Татарстан Республикасы Нурлат муниципаль районы белем бирү оешмаларында эшләүче педагогик хезмәткәрләргә - яшь белгечләргә Татарстан Республикасы бюджетыннан бирелә торган акчалар исәбеннән айлык кызыксындыру өстәмәсе бирү тәртибен раслау турында» 29.08.2019 ел, 744 номерлы карары, «Үзгәрешләр кертү турында» 22.07.2021 ел, 710 номерлы карары үз көчен югалткан дип санарга .

3. Әлеге карарның үтәлешен тикшереп торуны Нурлат муниципаль районы Башкарма комитеты җитәкчесенең социаль мәсьәләләр буенча урынбасарына йөкләргә.

Җитәкче Р.Р.Хәмзин